# Битарафлык дигән заман чире Күңелләрдә урын алмасын.




# 22 апрель - Бөтендөнья Җир көне

Без үзебезнең авылыбыз табигатен яратабыз һәм сакларга да тырышабыз. Һәр ел саен сыерчыкларыбыз кайтуга аларга яңа оялар ясап куябыз, чишмәләрне “карап” торабыз, Сабантуй була торган урынны чүп-чардан аралыйбыз, мәктәп өмәләрендә катнашабыз, һәйкәл мәйданын да чиста тотабыз, зират чистартуга да олылар белән берлектә зур өлеш кертәбез. Авылыбызны чиста тоту өчен эшлисе эшләр байтак әле.



# Син табигатькә ничек ярдәм итә аласың?

- *Үзең чүп-чар ташлама;*
- *язын һәм көзен өмәдә катнаш;*
- *аэрозольләр кулланмаска тырыш;*
- *агачлар, чәчәкләр утырт;*
- *урманда куркынычсызлык кагыйдә-ләрен төгәл үтә!*

*Табигатьнең матурлыгын күрә белгән кеше беркайчан да каты бәгырьле була алмый.*